# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Татарстан Республикасы Конституция суды турында" 1992 елның 22 декабрендәге Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

<u>1 статья.</u> "Татарстан Республикасы Конституция суды турында" 1992 елның 22 декабрендәге Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы җыелма басмасы, 1992, N 11-12), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

"Татарстан Республикасы Конституция суды турында
Татарстан Республикасы
З А К О Н Ы

Әлеге Закон Татарстан Республикасы Конституция судының оешуын һәм компетенциясен, аның судьялары статусын, конституциячел суд эшләрен алып бару принципларын, шулай ук Татарстан Республикасы Конституция судында аерым категория эшләрне алып бару үзенчәлекләрен билгели.

Беренче кисәк

Татарстан Республикасы Конституция судын оештыру һәм аның судьялары статусы

I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды – Татарстан Республикасында суд хакимияте органы

Татарстан Республикасы Конституция суды – Татарстан Республикасының конституциячел төзелешен, кеше һәм гражданның төп хокукларын һәм ирекләрен яклау, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә Татарстан Республикасы Конституциясенең өстенлеген һәм турыдан-туры гамәлдә булуын тәэмин итеп тору максатларында суд хакимиятен конституциячел суд эшләрен алып бару рәвешендә башкаручы конституциячел тикшереп торуның суд органы.

2 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды турындагы законнар

Татарстан Республикасы Конституция судының вәкаләтләре, аны төзү һәм аның эшчәнлек тәртибе, Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының статусы Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон белән билгеләнә.

3 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды вәкаләтләре

1. Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы эшләрне хәл итә:

1) Татарстан Республикасы законнарының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы норматив карарларының;

2) Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының норматив-хокукый актларының;

3) Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара шартнамәләренең.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары арасында компетенция турындагы бәхәсләрне карый.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның даими комиссияләре һәм Та-

тарстан Республикасы Дәүләт Советының Парламент контроле комитеты таләпләре буенча Татарстан Республикасы Президенты гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирә.

4. Татарстан Республикасы Конституция суды гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозуга карата шикаятьләре буенча, судларның таләпләре буенча Татарстан Республикасы законнарының яисә аларның аерым нигезләмәләренең, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының норматив карарларының, Татарстан Республикасы Президенты указларының яисә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карарларының конституциячеллеген тикшерә.

5. Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасына ия була.

6. Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен алып барганда башка судларның яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнарының компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне билгеләүдән һәм тикшереп чыгудан тыелып кала.

7. Татарстан Республикасының Конституция суды үзенең эчке эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Конституция суды регламентын кабул итә.

<u>4 статья.</u> Татарстан Республикасы Конституция суды составы, аны төзү тәртибе һәм вәкаләтләре чоры

1. Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сайлап куючы алты судьядан тора.

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе һәм Рәис урынбасары Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды составындагы судьяларның кимендә өчтән икесе булганда үз эшчәнлеген башкарырга хокуклы.

3. Татарстан Республикасы Конституция судының вәкаләтләре

билгеле бер вакыт белән чикләнми.

5 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлегенең төп принциплары

Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлегенең төп принциплары конституциячел законлылыктан, бәйсезлектән, коллегиальлектән, хәбәрдарлыктан, якларның үзара ярышучанлыгыннан һәм тигез хокуклылыгыннан гыйбарәт.

6 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды карарларының мәҗбүрилеге

Татарстан Республикасы Конституция судының үз компетенциясе чикләрендә кабул ителгән карарлары Татарстан Республикасының бөтен территориясендәге барлык дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, урындагы затлар, гражданнар һәм аларның берләшмәләре өчен мәҗбүри.

7 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлегенең гарантияләре

1. Татарстан Республикасы Конституция суды оешу ягыннан, финанс һәм матди-техник яктан теләсә нинди башка органнардан бәйсез була.

2. Татарстан Республикасы Конституция судын финанслау Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбеннән башкарыла, һәм ул конституциячел суд эшләрен алып баруны бәйсез рәвештә тулы күләмдә гамәлгә ашыру мөмкинлеген тәэмин итә.

Татарстан Республикасының республика бюджетында ел саен Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлеген тәэмин итәр өчен кирәкле акчалар аерым статья итеп карала, бу акчаларны Татарстан Республикасы Конституция суды мөстәкыйль тота.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды үз эшчәнлеген мәгълүмат һәм кадрлар белән мөстәкыйль һәм бәйсез тәэмин итә.

4. Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлегенең хокукый, оештыру, финанс, мәгълүмати, матди-техник, кадрлар

шартларын һәм әлеге Законда билгеләнгән башка шартларын ничек тә булса чикләү рөхсәт ителми.

## II бүлек. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы статусы

8 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы урынына кандидатка карата куелучы таләпләр

30 дан яшьрәк һәм 65 яшьтән олырак булмаган, сайлау хокукына ия, Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вазыйфаларын үтәү өчен кирәкле югары юридик квалификациягә һәм мораль сыйфатларга ия булган, югары юридик белеме, шулай ук гыйльми дәрәҗәсе йә юридик белгечлек буенча кимендә ун ел эш стажы булган Татарстан Республикасы гражданы Татарстан Республикасының Конституция суды судьясы итеп сайлана ала.

9 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы урынына сайлау тәртибе

1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясына кандидатларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тигез санда тәкъдим итәләр.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы урынына сайлау турындагы мәсьәләне Татарстан Республикасы Президентыннан һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисеннән тәкъдимнәр алынган көннән соң бер айдан да соңга калмыйча сессиядә карый.

3. Татарстан Республикасы Конституция судының һәр судьясы ул урынга индивидуаль тәртиптә сайлана. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы составының билгеләнгән санлы составыннан күпчелек тавышны җыйган зат Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы урынына сайланган дип санала.

4. Судья Татарстан Республикасы Конституция суды составыннан чыккан очракта, судьяның вакантлы урынына башка затны сайлау турындагы тәкъдимне Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты яисә Татарстан Респуб-

ликасы Дәүләт Советы Рәисе билгеләнгән тәртиптә кертәләр.

10 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы анты

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессиясендә Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы урынына сайланган затны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы билгеләгән тәртиптә ант иттертә.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессиясендә Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә түбәндәге эчтәлектә ант итә: "Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вазыйфаларын намуслы һәм вөҗданлы үтәргә, Татарстан Республикасының конституциячел төзелешен якларга, бу вакытта бары тик Татарстан Республикасы Конституциясенә генә буйсынырга тантаналы рәвештә ант итәм".

11 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы урынына туры килмәслек шөгыльләр һәм гамәлләр

1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы хакимиятнең вәкиллекле органнары депутаты була алмый, башка дәүләт яисә җәмәгать эш урыннарын били яисә саклап кала алмый, хосусый практика алып бара алмый, эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә алмый, шулай ук судья булып эшләгәндә, мөгаллимлек, фәнни һәм бүтән төрле иҗади эшчәнлектән гайре, башка түләүле эш белән шөгыльләнә алмый.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы, законлы вәкиллектән гайре, судта, арбитраж судта яисә башка органнарда яклау яисә вәкиллекне башкармаска, хокукларга ирешүдә һәм вазыйфалардан азат итүдә кемгә дә булса ярдәм күрсәтмәскә тиеш.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы сәяси фиркаләрдә һәм хәрәкәтләрдә тормаска, аларга матди ярдәм күрсәтмәскә, сәяси акцияләрдә катнашмаска, сәяси пропаганда яисә агитация алып бармаска, дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле

үзидарә органнарына сайлаулар буенча кампанияләрдә катнашмаска, сәяси фиркаләрнең һәм хәрәкәтләрнең съездларында һәм конференцияләрендә булмаска, бүтән төрле сәяси эшчәнлек белән шөгыльләнмәскә тиеш. Ул нинди дә булса җәмәгать берләшмәсенең җитәкче составына керә алмый.

4. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы, матбугатта, башка массакүләм мәгълүмат чараларында һәм теләсә нинди аудитория каршында чыгыш ясап, Татарстан Республикасының Конституция суды өйрәнүче яисә аның каравына кабул итеп алынган мәсьәлә буенча карар кабул ителгәнче, бу мәсьәләгә карата үз фикерен белдерергә хокуклы түгел.

5. Әлеге статьяның нигезләмәләре Татарстан Республикасының Конституция суды судьясының, граждан һәм сайлаучы буларак, сайлауларда һәм референдумда тавыш бирү юлы белән үз ихтыярын ирекле белдерү хокукларын чикләмиләр.

## 12 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының вәкаләтләре чоры

1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы бу урынга ун елга сайлана. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы бу эш урынында җитмеш яшькә кадәр эшли ала.

Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы урынына икенче чорга сайлау рөхсәт ителми.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы ант биргән мизгеленнән үз вазыйфаларына керешкән дип санала. Вәкаләтләре чоры узгандагы яисә аңа җитмеш яшь тулгандагы айның соңгы көнендә аның вәкаләтләре туктатыла.

3. Вәкаләтләр чоры узган Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы үзе катнашында башланган эш буенча йомгаклау карары кабул ителгәнче вазыйфаларын үтәүне дәвам итә.

## 13 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы бәйсезлеге гарантияләре

Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының бәйсезлеге аның әлеге Законда билгеләнгән алыштыргысызлыгы, кагылгысызлыгы, судьяларның тигез хокуклылыгы, судья вәкаләтлә-

рен туктатып тору һәм туктату тәртибе, отставкага китү хокукы, конституциячел суд эшләрен алып баруның билгеләнгән процедурасының мәҗбүрилеге, суд эшчәнлегенә нинди дә булса тыкшынуның тыелуы, судьяга матди һәм социаль тәэминат бирү белән, аның югары статусына туры килерлек иминлек гарантияләре белән тәэмин ителә.

14 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының алыштыргысызлыгы

1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вәкаләтләре чорында алыштыргысыз була.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вәкаләтләре бары тик әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә һәм нигезләрдә генә туктатылырга яисә туктатып торылырга мөмкин.

15 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының кагылгысызлыгы

Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә кагылгысызлыкка ия була.

16 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары хокукларының тигезлеге

1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары бертигез хокуклардан файдаланалар.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында каралучы барлык мәсьәләләр буенча хәлиткеч тавыш хокукына ия була.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары үзләренең үзенчәлекле фикерләрен, тәкъдимнәрен һәм таләпләрен бергәләп бәян итәргә хокуклы түгел.

4. Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе һәм Рәис урынбасарының вәкаләтләре әлеге Закон белән билгеләнә.

5. Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе һәм Рәис урынбасары әлеге Законда Татарстан Республикасы Конституция

суды судьялары өчен билгеләнгән барлык процессуаль вәкаләтләрне башкаралар.

17 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының дәүләт органнары утырышларында катнашу хокукы

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе, Рәис урынбасары һәм башка судьялары Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең теләсә кайсы органы утырышында, шул исәптән ябык утырышында да, катнашырга хокуклы.

18 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының дәүләт яклавына хокукы

1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы һәм аның мөлкәте дәүләтнең махсус яклавында булалар.

2. Әгәр судьядан тиешле гариза керсә, Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының, аның гаилә әгъзаларының иминлеген, аның мөлкәтенең сакланылышын тәэмин итү өчен кирәкле чараларны иминлек тәэмин итүче органнар кулланалар.

19 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы бәйсезлегенең матди гарантияләре

Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы бәйсезлегенең матди гарантияләре Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән нормалар буенча гамәлгә ашырыла.

20 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының вәкаләтләрен туктатып тору

1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының вәкаләтләре түбәндәге нигезләрнең берсе булганда туктатып торылырга мөмкин:

1) судьяны сак астына алуга яисә аны җинаять җаваплылыгына тартуга Татарстан Республикасы Конституция судының ризалыгы булса;

2) судья сәламәтлеге аркасында үз вазыйфаларын вакытлыча (рәттән дүрт айдан да артыграк) башкара алмаса.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының вәкаләтләре аларны туктатып торырлык сәбәпләр ачылган көннән соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан кабул ителгән карар нигезендә туктатып торыла.

3. Татарстан Республикасы Конституция судының вәкаләтләре туктатылып торылган судьясы Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында катнашырга, шулай ук дәүләт органнарына һәм оешмаларына, җәмәгать берләшмәләренә, урындагы затларга һәм гражданнарга рәсми документлар җибәрергә һәм алардан нинди дә булса документлар һәм башка төрле мәгълүмат соратып алырга хокуклы түгел.

4. Татарстан Республикасы Конституция суды судьяның вәкаләтләрен әлеге вәкаләтләрне туктатып тору сәбәпләре беткәнче туктатып тора.

Судьяның вәкаләтләрен торгызу Татарстан Республикасы Конституция суды карары белән рәсмиләштерелә.

<u>21 статья.</u> Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының вәкаләтләрен туктату

1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының вәкаләтләре түбәндәгеләр аркасында туктатыла:

1) Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы урынына сайлап куюның Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм әлеге Законда билгеләнгән тәртибе бозылса;

2) судьяның вәкаләтләр чоры узса яисә судья бу урында эшләүнең иң чик яшенә җитсә;

3) бу урында эшләүнең иң чик яшенә җиткәнче үк судья отставка турында язмача шәхси гариза бирсә;

4) судья Татарстан Республикасы гражданлыгын югалтса;

5) судьяга карата чыгарылган гаепләү хөкем карары закон көченә керсә;

6) судья намусын һәм абруен хурларлык яисә суд хакимиятенең абруен төшерерлек гамәлләр кылса;

7) Татарстан Республикасы Конституция суды кисәтүгә карамастан, судья үзенең эш урынына туры килмәслек шөгыльләрен яи-

сә гамәлләрен дәвам итсә;

8) судья Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында катнашмаса яисә мәгълүм сәбәпләрсез тавыш бирүдән рәттән өч тапкырдан да артыграк баш тартса;

9) закон көченә кергән суд карары судьяны хезмәткә сәләтсез дип таныса;

10) закон көченә кергән суд карары судьяны хәбәрсез югалган яисә вафат булган дип таныса;

11) судья вафат булса.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы шулай ук сәламәтлеге аркасында хезмәткә сәләтсез булса яисә мәгълүм сәбәпләр аркасында озак вакыт эчендә (кимендә ун ай рәттән) судья вазыйфаларын үти алмаса, аның вәкаләтләре туктатылырга мөмкин.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының вәкаләтләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән туктатыла.

4. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вәкаләтләре туктау белән бергә шулай ук аның Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе һәм Рәис урынбасары сыйфатындагы вәкаләтләре дә туктатыла.

<u>22 статья.</u> Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының отставкасы

1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының вәкаләтләре әлеге Законның 21 статьясындагы беренче өлешенең 2, 3 һәм 9 пунктларында һәм икенче өлешендә каралган сәбәпләр аркасында туктатылган булса, ул отставкада дип санала.

2. Отставкадагы судьяга Татарстан Республикасы законнары нигезендә гомуми нигезләрдә пенсия яисә гомере буена ай саен акча бирелә.

3. Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьясына шулай ук Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән отставкадагы судья статусының башка нигезләмәләре дә кагыла.

23 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының квалификация классы

Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына, билгән эш урынына, судья урынындагы эш стажына һәм законда каралган башка хәлләргә бәйле рәвештә, квалификация класслары бирелә.

## III бүлек. Татарстан Республикасы Конституция судының структурасы һәм эшчәнлеген оештыру

24 статья. Конституциячел суд эшләрен алып баруның оештыру рәвешләре

1. Татарстан Республикасы Конституция суды эшләрне Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында карый һәм хәл итә.

Утырышларда Татарстан Республикасы Конституция судының барлык судьялары да катнаша.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе, Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисе, Татарстан Республикасы Прокуроры катнаша ала, алар каралучы барлык мәсьәләләр буенча үз позицияләрен белдерергә хокуклы.

25 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе

1. Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе:

1) Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларын әзерләүгә җитәкчелек итә, аларны чакыра һәм аларда рәислек итә;

2) Татарстан Республикасы Конституция суды тикшерүенә утырышларда каралырга тиешле мәсьәләләрне кертә;

3) Конституция суды судьяларына эшләр, йомышлар куша;

4) дәүләт органнары һәм оешмалары, җәмәгать берләшмәләре белән мөнәсәбәтләрдә Татарстан Республикасы Конституция суды

исеменнән эш йөртә;

5) Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты белән гомуми җитәкчелек итә, Конституция суды аппараты җитәкчесен һәм аның бүлекчәләре җитәкчеләрен билгели;

6) әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы Конституция суды регламенты нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе Татарстан Республикасы Конституция судын тоту һәм аның эшчәнлеген тәэмин итүгә билгеләнгән бюджет ассигнованиеләре белән эш итүче булып тора.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе боерыклар һәм күрсәтмәләр чыгара.

<u>26 статья.</u> Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе вазыйфаларын вакытлыча үтәү

1. Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе үз вазыйфаларын башкара алмаган барлык очракларда, аларны вакытлыча Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе урынбасары башкара.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе урынбасарының Рәис вазыйфаларын башкара алу мөмкинлеге булмаганда, бу вазыйфаларны вакытлыча башкару Татарстан Республикасы Конституция судының яше буенча иң өлкән судьясына күчә.

<u>27 статья.</u> Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе урынбасары

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе урынбасары Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе күрсәтмәсе буенча аның аерым вазыйфаларын гамәлгә ашыра, шулай ук Татарстан Республикасы Конституция суды үзенә йөкләгән вазыйфаларны да башкара.

<u>28 статья.</u> Татарстан Республикасы Конституция суды регламенты

Татарстан Республикасы Конституция суды регламентында Та-

тарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон нигезендә түбәндәгеләр билгеләнә: утырышларда эшләрне карау чиратын билгеләү тәртибе; утырышлардагы процедура һәм этикет кагыйдәләре; судьяларның эшен оештыру һәм алар арасында эш бүлешү принциплары, аларны специальләштерү мөмкинлеген дә кертеп; Татарстан Республикасы Конституция судында эшләр алып бару тәртибе; Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты хезмәткәрләренә карата таләпләр; Татарстан Республикасы Конституция судының эчке эш тәртибе кагыйдәләре; Татарстан Республикасы Конституция судының эчке эшчәнлеге буенча башка мәсьәләләр.

## Икенче кисәк

## Татарстан Республикасы Конституция судында эшләр алып баруның гомуми кагыйдәләре

### IV бүлек. Конституциячел суд эшләрен алып бару принциплары

<u>29 статья.</u> Конституциячел законлылык

Татарстан Республикасы Конституция суды һәм аның судьялары, Татарстан Республикасы Конституциясенең өстенлеген һәм турыдан-туры гамәлдә булуын хуплап, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә конституциячел законлылыкны үз компетенцияләре чикләрендә тәэмин итәләр.

<u>30 статья.</u> Бәйсезлек

1. Татарстан Республикасы Конституция суды һәм аның судьялары үз вәкаләтләрен башкарганда бәйсез булалар, бары тик Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм әлеге Законга гына таяналар.

2. Татарстан Республикасы Конституция судының карарлары һәм башка актлары, судьяларның үзенчәлекле фикерләре судьяларның хокукый позициясен белдерәләр.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары үз ихтыярларын ирекле белдерүгә чит йогынтылар булмаслык шартлар-

да карар кабул итәләр. Алар Татарстан Республикасы Конституция суды алдан өйрәнү йә карау өчен кабул итеп алган мәсьәләләр буенча кемнән дә булса күрсәтмәләр соратып алырга яисә алырга хокуклы түгел.

4. Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлегенә ничек тә булса катышу рөхсәт ителми, һәм бу законда каралган җаваплылыкка китерә.

31 статья. Коллегиальлек

1. Эшләрне һәм мәсьәләләрне карау, шулай ук алар буенча карарлар кабул итү Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан коллегиаль рәвештә башкарыла. Карарлар бары тик суд утырышында эшне карауда катнашкан судьялар тарафыннан гына кабул ителә.

2. Утырышларда судьяларның гомуми санының өчтән ике өлеше катнашканда, Татарстан Республикасы Конституция суды карарлар кабул итәргә хокуклы була. Кворумны билгеләгәндә эшне карауда катнашудан читләштерелгән судьялар һәм вәкаләтләре туктатылган судьялар исәпкә алынмый.

32 статья. Хәбәрдарлык

Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында эшләрне карау ачык алып барыла. Әлеге Законда каралган очракларда гына ябык утырышлар уздыру рөхсәт ителә. Ачык утырышларда да , ябык утырышларда да кабул ителгән карарлар халыкка игълан ителә.

33 статья. Эшләрне карап тикшерүне телдән башкару

1. Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында эшләрне карап тикшерү телдән башкарыла. Эшләрне карап тикшерү барышында Татарстан Республикасы Конституция суды якларның аңлатуларын, экспертларның күрсәтүләрен тыңлый, булган документларны игълан итә.

2. Судьяларга һәм якларга танышу өчен бирелгән йә утырышта шушы эш буенча эчтәлеге бәян ителгән документлар Татарстан

Республикасы Конституция суды утырышында игълан ителмәскә дә мөмкин.

34 статья. Конституциячел суд эшләрен алып бару теле

1. Татарстан Республикасы Конституция судында эшләр Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә алып барыла.

2. Процесста дәүләт телләрен белмәүче катнашучылар туган телләрендә чыгыш ясый, аңлатулар бирә һәм тәрҗемәче хезмәтләреннән файдалана алалар.

35 статья. Суд утырышының өзексезлеге

1. Ял итү өчен яисә процесста катнашучыларны эшне карап тикшерүне дәвам итүгә әзерләү әчен, шулай ук утырышның нормаль барышына комачауларлык шартларны бетерү өчен билгеләнгән вакыттан гайре, һәр эш буенча Татарстан Республикасы Конституция суды утырышы өзексез алып барыла.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды эш буенча карар кабул иткәнче яисә аны кичектергәнче үз утырышында башка эшләрне карый алмый.

36 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды карарын кичектереп тору

Әгәр Татарстан Республикасы Конституция суды мәсьәлә җитәрлек әзерләнмәгән дип, килүләре мәҗбүри саналган яклар яисә эксперт килми калу, шулай ук тиешле материаллар бирелеп бетмәү аркасында өстәмә өйрәнүгә мохтаҗ дип санаса, эшне карау кичектереп торылырга мөмкин. Бу очракта Татарстан Республикасы Конституция суды утырышның кайсы көнгә күчерелүен билгели. Каралуы кичектереп торылган эш буенча утырыш башыннан ук яисә кичектереп торылган мизгеленнән башланып китә.

37 статья. Беркетмәләштерү

Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында беркетмә алып барыла, аңа карата таләпләр Татарстан Республикасы

Конституция судының регламенты белән билгеләнә.

38 статья. Якларның ярышучанлыгы һәм тигез хокуклылыгы

Яклар Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында ярышучанлык нигезендә үз позициясен яклау буенча бертигез хокуклардан һәм мөмкинлекләрдән файдаланалар.

## V бүлек. Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү

39 статья. Татарстан Республикасы Конституция судында эшләрне карау сәбәпләре һәм нигезләре

1. Татарстан Республикасы Конституция судына таләп, үтенечнамә яисә шикаять рәвешендә әлеге Закон таләпләренә туры китереп мөрәҗәгать итү Татарстан Республикасы Конституция судында эшләрне карау өчен сәбәп була.

2. Түбәндәгеләр эшләрне карау өчен нигез була:

1) Татарстан Республикасы законының, аның башка норматив-хокукый актының, үз көченә кермәгән халыкара шартнамәсенең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы мәсьәләгә ачыклык кертергә кирәк булса;

2) компетенцияләр турындагы бәхәсләрдә яклар позицияләрендә вәкаләтләргә ия булу турында каршылык туса;

3) Татарстан Республикасы Президенты гамәлләренең һәм карарларының конституциячел булмавы гаепләнсә.

40 статья. Мөрәҗәгатькә карата гомуми таләпләр

1. Мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Конституция судына язма рәвештә җибәрелә һәм аңа вәкаләтле зат (вәкаләтле затлар) тарафыннан имза салына.

2. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

1) мөрәҗәгать җибәрелүче орган буларак Татарстан Республикасы Конституция суды;

2) гариза бирүченең исеме (гражданның шикаятендә - фами-

лиясе, исеме, атасының исеме), адресы һәм гариза бирүче турында башка белешмәләр;

3) мөрәҗәгать итүченең вәкиле турында кирәкле белешмәләр һәм аның вәкаләтләре, вәкиллек эш урыны буенча гамәлгә ашырылган очраклар моңа керми;

4) тикшерелергә тиешле актны бастырып чыгарган йә компетенцияләр турындагы бәхәстә катнашучы дәүләт органының исеме һәм адресы;

5) Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм әлеге Законның Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итәрлек хокук бирүче нормалары;

6) тикшерелергә тиешле актның төгәл исеме, номеры, кабул ителгән көне, басылган чыганагы турында һәм башка белешмәләр;

7) мөрәҗәгатьне Татарстан Республикасы Конституция суды карарлык әлеге Законда күрсәтелгән конкрет нигезләр;

8) мөрәҗәгать итүченең үзе күтәргән мәсьәләгә карата позициясе һәм аны, Татарстан Республикасы Конституциясенең тиешле нормаларына таянып, хокукый нигезләве;

9) гозер, үтенечнамә, шикаять белән Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать ителгән таләп;

10) мөрәҗәгатькә кушып бирелүче документлар исемлеге.

<u>41 статья.</u> Мөрәҗәгатькә кушып бирелүче документлар

1. Татарстан Республикасы Конституция судына җибәрелүче мөрәҗәгатькә түбәндәгеләр кушып бирелә:

1) тикшерелүче актның тексты;

2) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы ышанычнамә яисә башка документ, моңа эш урыны буенча вәкиллек очраклары керми, шулай ук Татарстан Республикасы Конституция судында вәкил буларак чыгыш ясаучы затның хокукын раслаучы документларның күчермәләре;

3) дәүләт пошлинасын түләү турында документ.

2. Мөрәҗәгатькә Татарстан Республикасы Конституция суды утырышына чакырылырга тәкъдим ителүче экспертлар исемлеге, шулай ук документлар һәм материаллар кушып бирелергә мөмкин.

3. Мөрәҗәгать һәм аңа әлеге статьяның беренче өлеше нигезендә кушып бирелүче документлар һәм башка материаллар Татарс-

тан Республикасы Конституция судына дәүләт органнары, учреждениеләр, оешмалар тарафыннан күчермәләре белән бергә алты нөсхәдә бирелә, гражданнар тарафыннан күчермәләре белән бергә өч нөсхәдә бирелә.

42 статья. Дәүләт пошлинасы

1. Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать иткән өчен түбәндәге күләмнәрдә дәүләт пошлинасы түләнә:

таләп һәм үтенечнамә өчен - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләмендә;

юридик затның шикаяте өчен - хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләмендә;

гражданның шикаяте өчен - хезмәт өчен түләүнең бер минималь күләмендә.

Дәүләт пошлинасы хезмәт өчен түләүнең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән минималь күләме буенча исәпләнә.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды үзенең карары белән гражданны, аның матди хәлен исәпкә алып, дәүләт пошлинасын түләүдән азат итә йә аның күләмен киметә ала.

3. Судларның таләпләре, Татарстан Республикасы Президенты гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы таләпләр өчен пошлина түләнми.

4. Мөрәҗәгать карауга алынмаган очракларда дәүләт пошлинасы кире кайтарып бирелә.

5. Дәүләт пошлинасы мөрәҗәгатьне Татарстан Республикасы Конституция судына биргәнче түләнә һәм Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә.

## VI бүлек. Мөрәҗәгатьләрне алдан карау

43 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты тарафыннан мөрәҗәгатьләрне карау

1. Татарстан Республикасы Конституция судына керүче мөрәҗәгатьләр Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты тарафыннан һичшиксез теркәлергә тиеш.

230

2. Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты мөрәҗәгать итүчегә түбәндәге очракларда аның мөрәҗәгатенең әлеге Закон таләпләренә туры килмәве турында хәбәр итә:

1) мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына туры килмәсә;

2) рәвеше буенча әлеге Закон таләпләренә туры килмәсә;

3) тиешсез органнан яисә заттан бирелгән булса;

4) дәүләт пошлинасы түләнмәгән булса.

3. Әлеге статьяның икенче өлешендәге 2 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән җитешсезлекләр бетерелгәч, мөрәҗәгать итүче үзенең мөрәҗәгатен Татарстан Республикасы Конституция судына кабат җибәрергә хокуклы.

4. Әгәр мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына туры килмәсә, Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты аны шунда куелган мәсьәләләрне хәл итәргә вәкаләтле дәүләт органнарына яисә оешмаларына җибәрергә мөмкин.

<u>44 статья.</u> Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары тарафыннан мөрәҗәгатьне алдан өйрәнү

1. Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе Татарстан Республикасы Конституция суды билгеләгән тәртиптә берәр яисә берничә судьяга мөрәҗәгатьне алдан өйрәнүне йөкли, алдан өйрәнү мөрәҗәгатьне теркәгән көннән бер айдан да соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш.

2. Мөрәҗәгатьне судьяның (судьяларның) алдан өйрәнүе Татарстан Республикасы Конституция судында эшләрне алып баруның мәҗбүри стадиясе була.

3. Мөрәҗәгатьне алдан өйрәнү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы (судьялары) бәяләмәсе турында Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында хәбәр ителә.

<u>45 статья.</u> Мөрәҗәгатьне карауга кабул итү

1. Судья (судьялар) мөрәҗәгатьне алдан өйрәнүне тәмамлаган көннән бер айдан да соңга калмыйча утырышта Татарстан Рес-

публикасы Конституция суды мөрәҗәгатьне карауга кабул итү турындагы мәсьәлә буенча карар кабул итә.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды кабул иткән карар турында якларга хәбәр ителә.

3. Кичектергесез очракларда Татарстан Республикасы Конституция суды дәгъваланучы актның гамәлдә булуын, Татарстан Республикасының дәгъваланучы халыкара шартнамәсенең үз көченә керү процессын Татарстан Республикасы Конституция суды эшләрне карап бетергәнче туктатып тору тәкъдиме белән тиешле органнарга һәм урындагы затларга мөрәҗәгать итә ала.

<u>46 статья.</u> Мөрәҗәгатьне карауга кабул итүдән баш тарту

1. Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәге очракларда мөрәҗәгатьне карауга кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә:

1) мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына кермәгән булса;

2) мөрәҗәгать әлеге Закон таләпләре нигезендә бирелергә тиеш булмаган булса;

3) мөрәҗәгать итү предметы буенча элегрәк Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан үз көчен саклаучы карар чыгарылган булса.

2. Конституциячеллеге дәгъваланучы акт юкка чыгарылган булса яисә эшне карый башлаганчы йә аны карау чорында үз көчен югалткан булса, Татарстан Республикасы Конституция суды башлаган эш туктатып торылырга мөмкин, моңа бу актның гамәлдә булуы аркасында гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирегә бозылган очраклар керми.

<u>47 статья.</u> Мөрәҗәгатьне кире алу

Татарстан Республикасы Конституция судына бирелгән мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында эшне карый башлаганчы ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан кире алынырга мөмкин. Мөрәҗәгать кире алынган очракта эшне карау туктатыла.

## VII бүлек. Татарстан Республикасы Конституция судында эшләрне карауның гомуми процедура кагыйдәләре

### 48 статья. Утырышлар чакыру

Татарстан Республикасы Конституция суды утырышлары Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе тарафыннан чакырыла.

### 49 статья. Утырышларда мәсьәләләрне карау тәртибе

Әгәр әлеге Законда яисә Татарстан Республикасы Конституция суды регламентында башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында мәсьәләләрне карауның бердәм тәртибе кулланыла.

### 50 статья. Эшләрне тыңлауга билгеләү

Эшләрне Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында тыңлауга билгеләү турында карар мөрәҗәгатьне карарга кабул иткәннән соң бер айдан да соңга калмыйча утырышта Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан кабул ителә. Карарда эшләрне тыңлауның чираты күрсәтелә.

### 51 статья. Эшне тыңлауга әзерләү

1. Эшне тыңлауга әзерләү, Татарстан Республикасы Конституция суды карарының проектын әзерләү өчен, шулай ук утырышта материалларны бәян итү өчен Татарстан Республикасы Конституция суды бер яисә берничә судьяны нотыкчы итеп билгели.

2. Мөрәҗәгатьне өйрәнгәндә һәм тыңлауга әзерләгәндә нотыкчы Татарстан Республикасы Конституция суды вәкаләтләре нигезендә кирәкле документлар һәм башка материаллар таләп итә, тикшерүләр алып барырга, тикшеренүләр уздырырга, экспертизалар ясарга куша, белгечләр консультациясеннән файдалана, таләпләр җибәрә.

3. Нотыкчы судья һәм Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе утырышка чакырылырга һәм чакыртып китерелергә тиеш-

ле затлар даирәсен билгели, утырышның урынын һәм вакытын хәбәр итү турында, шулай ук процесста катнашучыларга тиешле материалларны җибәрү турында күрсәтмәләр бирә.

52 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды таләпләре

1. Норматив-хокукый актларның, документларның текстларын һәм аларның күчермәләрен, эшләрне, белешмәләрне һәм башка материалларны бирү турында; документларның һәм норматив актларның текстларын таныклау турында; тикшерүләр алып бару, тикшеренүләр уздыру, экспертизалар ясау турында; аерым шартлар билгеләү турында; белгечләрне җәлеп итү турында; аңлатулар, консультацияләр бирү турында һәм каралучы эшләр буенча профессиональ фикерләрне бәян итү турында Татарстан Республикасы Конституция суды таләпләрен үзләренә адресланган барлык органнар, оешмалар һәм затлар тарафыннан үтәү мәҗбүри.

2. Әгәр Татарстан Республикасы Конституция суды башка вакыт билгеләмәгән булса, Татарстан Республикасы Конституция суды таләпләре аларны алган көннән бер ай эчендә каралырга тиеш һәм аларны карау нәтиҗәләре буенча җавап Татарстан Республикасы Конституция судына җибәрелергә тиеш.

3. Дәүләт органнары һәм оешмаларының Татарстан Республикасы Конституция суды таләпләрен үтәүгә бәйле чыгымнары шушы органнар һәм оешмалар исәбеннән тотыла. Башка оешмаларның һәм затларның чыгымнары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән түләнә.

4. Татарстан Республикасы Конституция суды таләпләрен үтәмәү йә тиешенчә үтәмәү, шулай ук Татарстан Республикасы Конституция судын күрәләтә ялгыш юлга кертү законнарда билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

53 статья. Процесста катнашучылар

Яклар, аларның вәкилләре, экспертлар, тәрҗемәчеләр Татарстан Республикасы Конституция суды процессында катнашучылар дип санала.

54 статья. Яклар һәм аларның вәкилләре

1. Түбәндәгеләр Конституция суды эшләрендә катнашучы яклар булалар:

1) мөрәҗәгать итүчеләр - Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать җибәрүче органнар яисә затлар;

2) конституциячеллеге тикшерелергә тиешле актларны бастырып чыгарган йә шуларга имза салган органнар яисә урындагы затлар;

3) компетенцияләре дәгъваланучы дәүләт органнары;

4) гамәлләренең һәм карарларының конституциячеллеге турында бәяләмә бирелүче Татарстан Республикасы Президенты һәм аның вәкилләре.

2. Якларның эш урыны буенча вәкилләре булып түбәндәгеләр катнаша ала:

Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгатькә имза салган органның җитәкчесе;

дәгъваланучы актны бастырып чыгаручы яисә компетенцияләр турындагы бәхәстә катнашучы органның җитәкчесе;

дәгъваланучы актка имза салучы урындагы зат;

таләп белән мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы халык депутаты.

Шулай ук адвокатлар яисә вәкаләтләре тиешле документлар белән расланучы, югары юридик белемле затлар да якларның вәкилләре була алалар. Һәр яктан да вәкилләр саны өчтән артык була алмый.

3. Яклар бертигез процессуаль хокукларга ия булалар. Яклар һәм аларның вәкилләре эш материаллары белән танышырга, әлеге эш буенча үз позициясен бәян итәргә, процесста катнашучыларга сораулар бирергә, үтенечнамәләр, шул исәптән судьядан баш тарту турында да, бирергә хокуклы. Як мөрәҗәгатькә карата эш материалларына кушымта итеп теркәлергә тиешле язмача фикерләрен белдерә һәм икенче якның фикерләре белән дә таныша ала.

4. Яклар яисә аларның вәкилләре Татарстан Республикасы Конституция суды чакыруы буенча судка килергә, аңлатулар һәм сорауларга җаваплар бирергә тиеш. Әгәр як эшне аның катнашында карауны үтенгән һәм үзенең килмәвен мөһим сәбәпләр белән раслаган булса, якның яисә аның вәкиленең Татарстан Республикасы

Конституция суды утырышына килмәве эшне карауга комачауламый.

55 статья. Утырышлар

1. Татарстан Республикасы Конституция суды утырышлары ачык үтә.

2. Закон белән саклванучы серне саклап калу, гражданнарның иминлеген тәэмин итү, җәмәгать әхлагын яклау өчен кирәк булганда, Татарстан Республикасы Конституция суды ябык утырыш билгели.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды утырышын алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Конституция суды регламенты белән билгеләнә.

4. Утырышлар залында катнашучылар Татарстан Республикасы Конституция судына һәм анда кабул ителгән кагыйдәләргә һәм процедураларга ихтирамлы булырга, рәислек итүченең утырышны алып бару тәртибен үтәү турындагы күрсәтмәләренә буйсынырга тиешләр.

5. Утырышны алып бару тәртибен бозучы яисә рәислек итүченең законлы күрсәтмәләренә буйсынмаучы зат кисәтелгәннән соң залдан чыгарып җибәрелергә мөмкин.

56 статья. Судьяны эшне карауда катнашудан читләштерү

1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы түбәндәге очракларда эшне карауда катнашудан читләштерелергә мөмкин:

1) судья каралу предметы булган актны элеккеге эш урынына бәйле рәвештә кабул итүдә катнашкан булса;

2) судья яклар вәкилләренең туганы яисә ире йә хатыны булганга күрә, эшне хәл иткәндә аның объективлыгына шик туса;

3) судья каралучы мәсьәлә буенча әлеге Законның 11 статьясындагы дүртенче өлешендә билгеләнгән тәртиптә үз фикерен халыкка ачык белдерсә.

2. Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән сәбәпләр булганда, Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы эшне тыңлаулар башлаганчы ук аннан баш тартырга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясын эштә катнашудан читләштерү Татарстан Республикасы Конституция суды-

ның дәлилләнгән карары белән башкарыла, бу карар читләштерелергә тиешле судьяны тыңлаганнан соң шунда катнашучы судьяларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

57 статья. Утырышта рәислек итүче

1. Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе яисә, ул булмаганда, Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенең урынбасары рәислек итә.

Нотыкчы судья үзе хәбәр итүче эш буенча утырышта рәислек итә алмый.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында рәислек итүче, карап тикшерүнең билгеләнгән тәртибен, аның тулылыгын һәм һәрьяклы әзерлеген, аның барышының һәм нәтиҗәләренең теркәлүен тәэмин итү өчен кирәкле чаралар күреп, утырышка җитәкчелек итә; карап тикшерүне каралучы эшкә кагылышы булмаган бар нәрсәләрдән арындыра; судьяларга һәм процесста катнашучыларга чыгыш ясау өчен сүз бирә; процесста катнашучылар тикшерелүче эшкә кагылышы булмаган мәсьәләләр буенча чыгыш ясый башласалар, аларның чыгышларын өзә; чыгышларның эзлеклелеген башбаштакланып бозганда, рәислек итүченең таләпләрен ике тапкыр үтәмәгәндә, кискен һәм мәсхәрәле гыйбарәләр кулланганда, закон белән тыелган раслаулар һәм өндәмәләр игълан иткәндә, аларны сүз алудан мәхрүм итә.

58 статья. Мәсьәләләрне тикшереп чыгу тәртибе

1. Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында каралучы эшнең асылын тикшереп чыгу аны карауның сәбәпләре һәм нигезләре турында, мәсьәләнең асылы турында, булган материалларның эчтәлеге һәм эшне карауга әзерләнү буенча күрелгән чаралар турында нотыкчы судья мәгълүматыннан башлана. Нотыкчы судьяга Татарстан Республикасы Конституция судының башка судьялары да сораулар бирергә мөмкин.

2. Нотыкчы судьяның чыгышы тәмамлангач, Татарстан Республикасы Конституция суды яклар тәкъдимнәрен тыңлый һәм эшкә кагылышлы мәсьәләләрне тикшереп чыгу тәртибе турында карар кабул

237



итә.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды карары белән билгеләнгән тәртипне бары тик Татарстан Республикасы Конституция суды үзе генә үзгәртергә мөмкин. Эшләрне карау барышында Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының мәсьәләләрне тикшереп чыгу тәртибе буенча әйтелгән тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан кичектергесез карала.

59 статья. Якларның аңлатмалары

1. Татарстан Республикасы Конституция суды карары белән билгеләнгән тәртип нигезендә утырышта рәисек итүче якларга карала торган мәсьәләнең асылын аңлатып үтүне һәм үз карашларын нигезләү өчен хокукый дәлилләр китерүне тәкъдим итә. Якларның карарын аның берничә вәкиле хуплаган очракта, чыгышларның эзлеклелеге һәм күләме әлеге як тарафыннан билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы Конституция судында яклар һәм аларның вәкилләре үз чыгышларын сәяси белдерүләр һәм декларацияләр өчен файдаланмаска һәм дәүләт органнары, иҗтимагый берләшмәләр, процесста катнашучылар, урындагы затлар һәм гражданнар адресына хурлау сүзләре әйтмәскә тиеш.

Һәр якның аңлатмасы Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан тулысынча тыңлана.

Бер якның аңлатмасыннан соң аңа Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары һәм икенче як, ә Татарстан Республикасы Конституция суды рөхсәт итсә, экспертлар да сораулар бирергә мөмкин.

60 статья. Эксперт бәяләмәсе

1. Каралучы эшкә кагылышлы мәсьәләләр буенча махсус белемнәргә ия зат эксперт сыйфатында Татарстан Республикасы Конституция суды утырышына чакырылырга мөмкин. Эксперт бәяләмә бирергә тиешле мәсьәләләр нотыкчы судья йә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан билгеләнә.

2. Чыгыш ясау алдыннан эксперт белә торып ялган бәяләмәләр биргәне өчен юридик җаваплылыгы турында кисәтелә.

3. Эксперт Татарстан Республикасы Конституция суды рөхсәте нигезендә эш материаллары белән танышырга, якларга сораулар бирергә, шулай ук үзенә өстәмә материаллар бирүне сорап үтенечнамә белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. Бәяләмә биргәннән соң эксперт Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының һәм якларның өстәмә сорауларына җавап бирергә тиеш.

<u>61 статья.</u> Документларны тикшереп чыгу

1. Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында судьялар инициативасы яисә яклар үтенечнамәсе буенча документлар игълан ителергә мөмкин. Чынлыгына шик булган документлар игълан ителми.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды тикшереп чыккан документлар Татарстан Республикасы Конституция суды карары буенча төп нөсхәләрдә яисә таныкланган күчермәләрдә эш материалларына кушып бирелә.

<u>62 статья.</u> Якларның йомгаклау чыгышы

1. Суд тикшерүе беткәннән соң һәр якның йомгаклау чыгышы тыңлана. Татарстан Республикасы Конституция суды якларның үтенече буенча аларга йомгаклау чыгышларына әзерлек өчен вакыт бирергә мөмкин.

2. Яклар үзләренең йомгаклау чыгышларында Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан тикшереп чыгылмаган документларга һәм шартларга таянырга хокуклы түгел.

<u>63 статья.</u> Эш алып баруны туктату

Әгәр утырыш барышында мөрәҗәгатьне карауга кабул итүдән баш тартырлык сәбәпләр килеп чыкса, конституциячеллеге закон, башка норматив-хокукый акт, шартнамә белән тикшерелергә тәкъдим ителгән мәсьәлә Татарстан Республикасы Конституциясендә үзенең хәл ителешен тапмаса яисә үзенең характеры һәм мәгънәсе буенча конституциячел мәсьәләләр рәтенә кертелмәсә, Татарстан Республикасы Конституция суды эш алып баруны туктата.

64 статья. Эшне тыңлауның тәмамлануы

Татарстан Республикасы Конституция суды эш мәсьәләләрен тикшереп чыгуны тәгәлләнгән дип таныганнан соң утырышта рәислек итүче эшне тыңлауның тәмамлануын игълан итә.

65 статья. Йомгаклау карарын кабул итү буенча судьялар киңәшмәсе

1. Карала торган эш буенча ябык киңәшмәдә Татарстан Республикасы Конституция суды йомгаклау карары кабул итә.

2. Киңәшмәдә Татарстан Республикасы Конституция судының бары тик әлеге эшне караучы судьялары гына катнаша.

3. Киңәшмә барышында Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары фикер алышына торган мәсьәлә буенча үз позициясен иркле бәян итәргә һәм башка судьяларның үз позициясен ачыклауларын сорарга хокуклы. Киңәшмәдә чыгышларның саны һәм дәвамлылыгы чикләнергә мөмкин түгел.

4. Ябык киңәшмәдә катнашкан судьялар дискуссиянең эчтәлеген һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен фаш итәргә хокуклы түгел.

VIII бүлек. Татарстан Республикасы Конституция суды карарлары

66 статья. Карарларның төрләре

1. Татарстан Республикасы Конституция суды карары әлеге Закон нигезендә аның утырышында кабул ителә торган акттан гыйбарәт.

2. Әлеге Законның 3 статьясындагы беренче, икенче һәм дүртенче өлешләрендә санап кителгән теләсә кайсы мәсьәләнең асылы буенча Татарстан Республикасы Конституция судының йомгаклау карары карар дип атала. Карарлар Татарстан Республикасы исеменнән чыгарыла.

3. Әлеге Законның 3 статьясындагы өченче өлешендә санап кителгән мәсьәләләрнең асылы буенча Татарстан Республикасы Конституция судының йомгаклау карары бәяләмә дип атала.

4. Татарстан Республикасы Конституция судының йомгаклау

карары карау өчен мөрәҗәгать кабул ителгән көннән өч айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш. Карала торган мәсьәләнең катлаулылыгын яисә күләменең зурлыгын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды күрсәтелгән вакытны озайтырга мөмкин, әмма бер айдан да артыкка түгел.

5. Конституция суды эшчәнлеге барышында Татарстан Республикасы Конституция суды кабул итә торган барлык башка карарлар билгеләмәләр дип атала.

6. Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында шулай ук үз эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча да карарлар кабул ителә.

<u>67 статья.</u> Карар кабул итү

1. Татарстан Республикасы Конституция суды карары судьяларның исемле тавышы белән ачык рәвештә кабул ителә. Рәислек итүче барлык очракларда да ахырдан тавыш бирә.

2. Әгәр дә әлеге Законда башкасы каралмаган булса, тавыш бирүдә катнашучы судьяларның күпчелеге Татарстан Республикасы Конституция суды карарын хуплап тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала.

3. Әгәр дә Законның, башка норматив-хокукый актның, шартнамәнең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча карар кабул иткәндә тавышлар бертигез бүленсә, карар дәгъваланучы актның конституциячеллеге файдасына кабул ителгән дип санала.

4. Компетенцияләр турындагы бәхәсләр буенча Татарстан Республикасы Конституция суды карары күпчелек тавыш белән кабул ителә. Аны кабул иткәндә тавышлар икегә бүленгән очракта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

5. Әгәр Татарстан Республикасы Президенты гамәлләре һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүе турындагы карарны судьяларның гомуми саныннан кимендә өчтән икесе хуплап тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала.

6. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының тавыш биргәндә тыелып калырга яисә тавыш бирүдән тайпылырга хокукы юк.

68 статья. Карарларга карата таләпләр

1. Татарстан Республикасы Конституция суды карарлары Татарстан Республикасы Конституциясенә, әлеге Законга һәм Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында тикшереп чыгылган материалларга нигезләнергә тиеш.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану гамәлиятендәге мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив-хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән орган актының конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә яисә компетенциясенә карата гына карарлар кабул итә һәм бәяләмәләр бирә. Карар кабул иткәндә Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

4. Татарстан Республикасы Конституция суды карарлары һәм бәяләмәләре аерым документлар рәвешендә бәян ителә, аларны кабул итү сәбәпләрен күрсәтү мәҗбүри.

5. Әлеге Законда яисә Татарстан Республикасы Конституция суды карарында башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы Конституция суды билгеләмәләре утырышта игълан ителә.

69 статья. Карарны бәян итү

1. Татарстан Республикасы Конституция судының аерым документ буларак бәян ителә торган карарында каралучы мәсьәләнең характерына бәйле түбәндәге белешмәләр була:

1) карарның исеме, аны кабул итү көне һәм урыны;

2) Татарстан Республикасы Конституция судының карар кабул иткән персональ составы;

3) яклар турында кирәкле белешмәләр;

4) карала торган мәсьәләнең формулировкасы, аны карау сәбәпләре һәм нигезләре;

5) Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм әлеге Законның Татарстан Республикасы Конституция судына бу мәсьәләне

карарга хокук бирә торган нормалары;

6) мөрәҗәгатьтәге таләпләр;

7) Татарстан Республикасы Конституция суды билгеләгән факттагы хәлләр һәм башка хәлләр;

8) Татарстан Республикасы Конституциясенең һәм әлеге Законның Татарстан Республикасы Конституция суды карар кабул иткәндә таянган нормалары;

9) Татарстан Республикасы Конституция суды кабул иткән карар файдасына дәлилләр, ә кирәк булганда - шулай ук яклар раславын кире кагырлык дәлилләр;

10) карарның формулировкасы;

11) карарның катгыйлыгын һәм мәҗбүрилеген күрсәтү;

12) карарның үз көченә керү тәртибе, шулай ук аны үтәү һәм бастырып чыгару тәртибе, вакыты һәм үзенчәлекләре.

2. Татарстан Республикасы Конституция судының йомгаклау карары тавыш бирүдә катнашкан барлык судьялар тарафыннан имзалана.

<u>70 статья.</u> Судьяларның аерым фикере

Татарстан Республикасы Конституция суды карары белән килешмәгән Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы үзенең аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

Судьяның аерым фикере эш материалларына кушып бирелә һәм Татарстан Республикасы Конституция суды карары белән бергә бастырып чыгарылырга тиеш.

<u>71 статья.</u> Карарны игълан итү

1. Татарстан Республикасы Конституция суды карары, имзаланганнан соң, тулысынча Татарстан Республикасы Конституция судының ачык утырышында кичекмәстән игълан ителә.

Татарстан Республикасы Конституция суды карарлары һәм бәяләмәләре имзаланганнан соң ике атнадан да соңга калмыйча түбәндәгеләргә җибәрелә:

Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына;

һәр якка;

Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республи-

касы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына;

Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Югары арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды карарлары шулай ук дәүләтнең башка органнарына һәм оешмаларына, җәмәгать берләшмәләренә, урындагы затларга һәм гражданнарга да җибәрелергә мөмкин.

72 статья. Карарны бастырып чыгару

Татарстан Республикасы Конституция суды карарлары һәм бәяләмәләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының рәсми басмаларында кичектергесез бастырып чыгарылырга тиеш.

Татарстан Республикасы Конституция суды карарлары шулай ук "Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре"ндә, кирәк булганда башка басмаларда бастырып чыгарыла.

73 статья. Карарның юридик көче

1. Татарстан Республикасы Конституция суды карары хәлиткеч, аңа карата шикаять белдерелми һәм игълан ителгәч үк үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды карары турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар, урындагы затлар тарафыннан расланууны таләп итми. Норматив-хокукый актның Конституциягә туры килмәвен тану турында Татарстан Республикасы Конституция суды карарының юридик көче шушы ук норматив-хокукый актны кабат кабул итү юлы белән юкка чыгарылмый.

3. Әгәр норматив-хокукый актның Конституциягә туры килмәвен тану хокукый җайга салуда бушлык китереп чыгарса, турыдан-туры Татарстан Республикасы Конституциясе кулланыла.

74 статья. Карарны үтәү вакытлары

Әгәр Татарстан Республикасы Конституция суды карарында башка вакыт махсус билгеләнмәгән булса, йә басылып чыкканнан

соң, йә аның рәсми тексты бирелгәннән соң ул кичекмәстән үтәлергә тиеш.

75 статья. Карарны үтәмәү нәтиҗәләре

Татарстан Республикасы Конституция суды карарын үтәмәү, тиешенчә үтәмәү йә үтәүгә тоткарлык ясау закон нигезендә билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

76 статья. Карардагы төгәлсезлекләрне төзәтү

Карар игълан ителгәннән соң Татарстан Республикасы Конституция суды карарда булган исемнәрдәге, билгеләрдәге төгәлсезлекләрне, хәреф хаталарын төзәтә һәм редакцияли, техник җитешсезлекләрне бетерә ала, бу хакта билгеләмә чыгара.

77 статья. Карарга аңлатма бирү

1. Татарстан Республикасы Конституция суды карарына бары тик Татарстан Республикасы Конституция суды гына, Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукы булган органнарның һәм затларның, карар җибәрелгән башка органнарның һәм затларның үтенечнамәсе буенча, үзенең утырышында рәсми төстә аңлатма бирә ала.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды карарына аңлатма бирү турындагы мәсьәлә үтенечнамә биргән орган яисә зат катнашында утырышта карала. Утырышка шулай ук карала торган эш буенча яклар сыйфатында катнашучы органнар һәм затлар чакырыла.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды карарына аңлатма бирү турында билгеләмә чыгарыла, ул аерым документ рәвешендә бәян ителә һәм карар басылып чыккан басмаларда нәшер ителергә тиеш.

78 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды карарларын яңадан карау

1. Татарстан Республикасы Конституция судының йомгаклау

карары Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан үз инициативасы буенча түбәндәге очракларда кабат каралырга мөмкин:

карар нигезләнеп кабул ителгән конституциячел норма үзгәргәндә;

карарны кабул иткән мизгелдә Татарстан Республикасы Конституция судына мәгълүм булмаган яңа җитди хәлләр ачыкланганда.

2. Әгәр Татарстан Республикасы Конституция судының хокукый позициясенә аңлатма бирү йомгаклау карарының гамәли эчтәлегенә яраклаштырып бирелмәсә, Татарстан Республикасы Конституция суды карарына аңлатма бирү турындагы билгеләмә кабат каралырга мөмкин.

<u>79 статья.</u> Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасында конституциячел законлылык торышы турындагы юлламасы

1. Татарстан Республикасы Конституция суды ел саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Президентына Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкның торышы турында юллама җибәрә.

2. Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкның торышы турындагы юлламасы аерым документ рәвешендә бәян ителә.

<u>80 статья.</u> Татарстан Республикасы Конституция судының штрафлар салу хокукы

1. Татарстан Республикасы Конституция суды, үзенең абруен яклап һәм конституциячел суд эшләренең нормаль барышын тәэмин итеп, судка карата ихтирамсызлык күрсәткән өчен әлеге Законда һәм җаваплылык турындагы законнарда каралган нигезләрдә һәм тәртиптә штрафлар салырга хокуклы.

2. Штраф салу турында Татарстан Республикасы Конституция суды билгеләмәсе чыгарыла, аңа каршылык һәм шикаять белдерелми.

3. Хокук бозучы штрафны үзенә штраф салыну турында хәбәр алганнан соң унбиш көннән дә соңга калмыйча түләргә тиеш. Күр-

сәтелгән вакыт эчендә штраф түләүдән баш тарткан яисә штрафны түләмәгән очракта Татарстан Республикасы Конституция судының штраф салу турындагы билгеләмәсен мәҗбүри үтәттерү административ хокук бозулар турында эшләр башкару кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

## Өченче кисәк
## Татарстан Республикасы Конституция судында аерым категориядәге эшләрне башкару үзенчәлекләре

### IX бүлек. Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив-хокукый актларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы эшләрне карау

**81 статья.** Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукы

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның даими комиссияләре һәм Парламент контроле комитеты, Татарстан Республикасы халык депутатларының биштән бер өлеше, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасы Югары суды, Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды, Татарстан Республикасы Прокуроры, дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органнары һәм районнарның, республика буйсынуындагы шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районнарның җирле администрацияләре Татарстан Республикасы Конституция судына Татарстан Республикасы законнарының һәм әлеге Законның 3 статьясындагы беренче өлешенең 1, 2 пунктларында күрсәтелгән башка норматив-хокукый актларының конституциячеллеген тикшерү турындагы таләп белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

**82 статья.** Таләп бирүнең мөмкин булуы

Әгәр мөрәҗәгать итүче законны яисә башка норматив-хокукый актны йә аларның аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәгәнлектән гамәлгә яраксыз дип яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының яки аның

урындагы затларының аларны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәгәнлектән кулланудан һәм үтәүдән баш тарту турында рәсми кабул ителгән карарларына каршы килеп, гамәлгә яраклы дип санаса, Татарстан Республикасы Конституция судына аларның конституциячеллеген тикшерү турында таләп бирү мөмкин була.

83 статья. Тикшерү чикләре

1. Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив-хокукый актларының түбәндәгеләр буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвен билгели:

1) нормаларның эчтәлеге буенча;

2) законның яисә башка норматив-хокукый актның рәвеше буенча;

3) кабул итү, нәшер итү, имзалау, бастырып чыгару яисә гамәлгә кертү тәртибе буенча;

4) закон чыгару, башкарма һәм суд хакимиятләренең Татарстан Республикасы Конституциясендә билгеләнгән бүленеше күзлегеннән чыгып;

5) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары арасында Татарстан Республикасы Конституциясендә билгеләнгән компетенцияне чикләү күзлегеннән чыгып;

6) Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясе арасында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр алып баруны һәм вәкаләтләрне бүлешү күзлегеннән чыгып.

2. Татарстан Республикасы Конституциясе үз көченә кергәнче кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарының яисә башка норматив-хокукый актларының конституциячеллеген тикшерү Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан бары тик нормаларның эчтәлеге буенча гына башкарыла.

84 статья. Эш буенча йомгаклау карары

1. Татарстан Республикасы законының яисә башка норма-

тив-хокукый актының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карау йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) Татарстан Республикасы законының яисә башка норматив-хокукый актының йә аларның аерым нигезләмәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүләрен тану турында;

2) Татарстан Республикасы законының яисә башка норматив-хокукый актның йә аларның аерым нигезләмәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәүләрен тану турында.

2. Татарстан Республикасы законын яисә башка норматив-хокукый актын йә аларның аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану конституциячел түгел дип танылган яки мөрәҗәгатьтә шундый нигезләмәләре күрсәтелгән актка нигезләнгән башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләрен юкка чыгаруга сәбәп була. Бу законнарның яисә башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләрен судлар, башка органнар һәм урындагы затлар куллана алмый.

## X бүлек. Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара шартнамәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәүләре турындагы эшләрне карау

### 85 статья. Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукы

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның даими комиссияләре һәм Парламент контроле комитеты, Татарстан Республикасы халык депутатларының биштән бер өлеше, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасы Югары суды, Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды, Татарстан Республикасы Прокуроры Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара шартнамәләренең конституциячел булуын тикшерү турындагы таләп белән Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

86 статья. Таләп бирүнең мөмкин булуы

Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара шартнамәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы таләп бирү мөмкин була, әгәр:

1) таләптә искә алынган Татарстан Республикасы халыкара шартнамәсе Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында ратификацияләнергә тиеш булса;

2) мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара шартнамәсен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәгәнлектән Татарстан Республикасында гамәлгә кертелергә һәм кулланылырга тиеш түгел дип санаса.

87 статья. Тикшерү чикләре

Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара шартнамәләренең түбәндәгеләр буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвен карый:

1) нормаларның эчтәлеге буенча;

2) шартнамә рәвеше буенча;

3) шартнамәләрне имзалау, төзү, бастырып чыгару яисә гамәлгә кертү тәртибе буенча;

4) закон чыгару, башкарма һәм суд хакимиятләренең Татарстан Республикасы Конституциясендә билгеләнгән бүленеше күзлегеннән чыгып;

5) Татарстан Республикасының югары дәүләт органнары арасындагы компетенцияләрне Татарстан Республикасы Конституциясендә билгеләнгәнчә чикләүләрдән чыгып.

88 статья. Эш буенча йомгаклау карары

1. Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара шартнамәсенең конституциячел булуын тикшерү турында эшне карау йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара

шартнамәсенең яисә аның аерым нигезләмәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүен тану турында;

2) Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара шартнамәсенең яисә аның аерым нигезләмәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәвен тану турында.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара шартнамәсенең яисә аның аерым нигезләмәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәве турында карары игълан ителгән мизгелдән халыкара шартнамә гамәлгә кертелергә һәм кулланылырга тиеш түгел, ягъни ратификацияләнә, раслана һәм Татарстан Республикасы өчен башкача үз көченә керә алмый.

## XI бүлек. Компетенция турындагы бәхәсләр буенча эшләрне карау

**89 статья.** Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукы

Татарстан Республикасы Конституциясенең 140 статьясындагы икенче өлешендә күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнары бәхәсендә катнашучыларның теләсә кайсы компетенция турындагы бәхәсне хәл итү хакында үтенечнамә белән Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукына ия.

**90 статья.** Үтенечнамә бирүнең мөмкин булуы

Әгәр:

1) дәгъваланучы компетенция Татарстан Республикасы Конституциясе, гамәлдәге законнар, Татарстан Республикасы шартнамәләре белән билгеләнсә, ә каршылыклар Татарстан Республикасы Конституция суды карамагында булса;

2) дәгъва эшнең суд карамагында булуы яисә хөкем итәлергә тиешлеге турындагы мәсьәләгә кагылмаса;

3) дәгъва башка алым белән хәл ителмәсә яисә хәл ителә алмаса;

4) мөрәҗәгать итүче норматив-хокукый актны бастырып чыгаруны яисә хокукый характердагы гамәл кылуны йә норматив-хоку-

кый акт бастырудан яки хокукый характердагы гамәл кылудан читләшүне дәүләт органнары арасындагы компетенцияләрнең Татарстан Республикасы Конституциясе тарафыннан билгеләнгән чикләнүен бозу дип санаса;

5) мөрәҗәгать итүче элек дәүләт хакимияте органнарының гариза бирүчеләр компетенциясен бозулары турында яисә әлеге органнарның үз компетенцияләренә керүче вазыйфаларын үтәүдән читләшүләре хакында язма гариза белән мөрәҗәгать иткән булса;

6) әлеге статьяның 5 пунктында искә алынган язмача гариза алынган көннән соң бер ай дәвамында анда күрсәтелгән хокук бозулар бетерелмәгән булса, үтенечнамә бирү мөмкин була.

91 статья. Тикшерү чикләре

1. Татарстан Республикасы Конституция суды компетенция турындагы дәгъваларны фәкать Татарстан Республикасы Конституциясе билгеләгән закон чыгару, башкарма һәм суд хакимияте бүленеше һәм Татарстан Республикасында дәүләт хакимияте органнары арасында компетенцияләрне чикләү күзлегеннән генә карый.

2. Компетенцияләр турында дәгъва предметы булган норматив акт нормаларының эчтәлеге, рәвеше, аңа кул кую, аны кабул итү, матбугатта бастыру яисә гамәлгә кертү тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү турындагы эшне карау бары тик аерым таләп нигезендә һәм Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының конституциячел булуы турында эшләрне карау тәртибенә туры китереп кенә мөмкин.

92 статья. Эш буенча йомгаклау карары

1. Компетенция турында дәгъваны карау йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) компетенция турындагы дәгъваның сәбәбе булып торган норматив-хокукый акт чыгарырга яисә хокукый характердагы гамәл кылырга дәүләт хакимиятенең тиешле органы вәкаләтләрен раслау турында;

2) компетенция турындагы дәгъваның сәбәбе булып торган

норматив-хокукый акт чыгарырга яисә хокукый характердагы гамәл кылырга дәүләт хакимиятенең тиешле органының вәкаләтләрен кире кагу турында.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды норматив-хокукый акт чыгаруны дәүләт хакимиятенең аны чыгаручы органы вәкаләтенә кермәвен таныса, акт карарда күрсәтелгән көннән үз көчен югалта.

XII бүлек. Татарстан Республикасы Президенты гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы эшләрне карау

<u>93 статья.</u> Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукы

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның даими комиссияләре һәм Парламент контроле комитеты Татарстан Республикасы Президенты гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турында бәяләмә бирү хакындагы таләп белән Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукына ия.

<u>94 статья.</u> Таләп бирүнең мөмкин булуы

Әгәр конституциячеллеген тикшерергә тәкъдим ителгән гамәлләр һәм карарлар, Татарстан Республикасы Конституциясенең 115 статьясының дүртенче өлешенә туры китереп, Татарстан Республикасы Президентын вазыйфасыннан азат итү өчен нигез булып торса, Татарстан Республикасы Президенты гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турында бәяләмә бирү хакында таләп, шулай ук әлеге мәсьәләне Татарстан Республикасы Конституция судының үз инициативасы буенча каравы мөмкин була.

<u>95 статья.</u> Тикшерү чикләре

Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Респуб-

ликасы Президенты гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвен Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Конституциясе чагылдырган вәкаләтләре күзлегеннән чыгып билгели һәм башка судлар, органнар компетенциясенә кергән барлык очракларда фактагы хәлләрне билгеләүдән һәм тикшерүдән тыелып кала.

96 статья. Таләпне җибәрү һәм бәяләмә бирү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Президенты гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турында бәяләмә бирү хакындагы таләп Татарстан Республикасы Конституция судына бәяләмә бирү турында карар кабул ителгәннән соң унбиш көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Гаепләү турындагы карар, әлеге мәсьәлә хакында таләпне җибәрүче орган утырышында фикер алышу беркетмәсе һәм стенограммасы текстлары, шушы фикер алышуга бәйле барлык документлар текстлары таләпкә кушып бирелә.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды бәяләмәсе таләпне теркәгәннән соң ун көннән дә соңга калмыйча бирелергә тиеш.

97 статья. Татарстан Республикасы Президенты гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы бәяләмә

1. Эшне карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәге бәяләмәләрнең берсен бирә:

1) Татарстан Республикасы Президенты гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүен тану турында;

2) Татарстан Республикасы Президенты гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәвен тану турында.

2. Татарстан Республикасы Президенты гамәлләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы Татарстан Республикасы Конституция суды

бәяләмәсе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Президентын Татарстан Республикасы Конституциясен бозган өчен вазыйфасыннан азат итү турында карар кабул ителгәндә исәпкә алына.

## XIII бүлек. Гражданнарның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозуга таләпләр, шикаятьләр буенча Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив-хокукый актларының конституциячеллеге турындагы эшләрне карау

<u>98 статья.</u> Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукы

1. Закон яки башка норматив-хокукый актлар белән үзләренең хокуклары һәм ирекләре бозылган гражданнар һәм аларның берләшмәләре конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозуга таләп яисә шикаять белән Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукына ия.

2. Таләпкә, шикаятькә, әлеге Законның 41 статьясында санап үтелгән документлардан тыш, эшне хәл иткәндә шикаять бирелгән Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив-хокукый актлары кулланылуы яки кулланылырга мөмкин булуын раслаучы документларның күчермәләре кушып бирелә. Гариза бирүчегә андый документларның күчермәсен бирү эшне караучы урындагы зат һәм орган тарафыннан гариза бирүче таләбе буенча башкарыла.

<u>99 статья.</u> Шикаять бирүнең мөмкин булуы

Конституциячел хокуклар һәм ирекләрнең бозылуына шикаять бирү Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив-хокукый акт белән мөмкин була, әгәр:

1) закон яисә башка норматив-хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса;

2) закон яисә башка норматив-хокукый акт, аны карау судта яисә башка органда тәгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса.

100 статья. Шикаятьне карауга кабул итү нәтиҗәләре

1. Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив-хокукый акты белән гражданнарның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозу буенча таләпне, шикаятьне карауга алып, шикаять бирелүче закон яисә башка норматив акт кулланылган яисә кулланылырга тиешле эшне караган судка яисә башка органга бу хакта хәбәр итә. Хәбәр итү эш буенча суд эшен туктатуга китерми.

2. Шикаять бирелүче закон яисә башка норматив-хокукый акт кулланылган яисә кулланылырга тиешле эшне караучы суд яисә башка орган Татарстан Республикасы Конституция суды карар кабул иткәнгә кадәр суд эшен туктатып торырга хокуклы.

101 статья. Тикшерү чикләре

Гражданнарның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозу буенча шикаятьтә күрсәтелгән Татарстан Республикасы законының яисә башка норматив-хокукый актының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвен Татарстан Республикасы Конституция суды тикшерүе чикләре әлеге Законның 83 статьясы белән билгеләнә.

102 статья. Эш буенча йомгаклау карары

1. Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив-хокукый акты белән гражданнарның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозу турындагы шикаятьне карау йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) Татарстан Республикасы законының яисә башка норматив-хокукый актының яки аның аерым нигезләмәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүен тану турында;

2) Татарстан Республикасы законының яисә башка норматив-хокукый актының яки аның аерым нигезләмәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәвен тану турында.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды конкрет эштә

кулланылган законны яисә башка норматив-хокукый актны яки аның аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип таныган очракта, әлеге эш теләсә кайсы очракта компетентлы орган тарафыннан гадәти тәртиптә каралырга тиеш.

Закон яисә башка норматив-хокукый акт яки аның аерым нигезләмәләре Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танылган очракта гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең суд чыгымнары билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Конституция судының конкрет эштә кулланылган законны яисә башка норматив-хокукый актны йә аның аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану турындагы карары гражданнарның таләпләре, шикаятьләре буенча шундый эшләрне Татарстан Республикасының вәкаләтле органнарының яңадан каравы өчен нигез булып тора.

## XIV бүлек. Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив-хокукый актларының конституциячеллеге турында эшләрне судларның таләпләре буенча карау

### <u>103 статья.</u> Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү

Суд эшне теләсә кайсы инстанциядә караганда, әлеге эштә кулланылган яисә кулланылырга тиешле Татарстан Республикасы законының яисә башка норматив-хокукый актының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәве турында нәтиҗә ясап, әлеге закон яисә башка норматив-хокукый актның конституциячеллеген тикшерү турында таләп белән Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итә.

### <u>104 статья.</u> Таләп бирүнең мөмкин булуы

Әгәр дә Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив-хокукый акты судта карала торган конкрет эштә кулланылса яки суд фикере буенча кулланылырга тиеш булса, суд таләбе бирү мөмкин була.

105 статья. Талөп кертүнең нәтиҗәләре

Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү турында суд карары чыгару мизгеленнән һәм Татарстан Республикасы Конституция суды карарын кабул итүгә кадәрге чорда эш алып бару яисә эш буенча суд чыгарган карарны башкару туктатып торыла.

106 статья. Тикшерү чикләре һәм йомгаклау карарларының төрләре

Суд таләбендә дәгъваланучы Татарстан Республикасы законының һәм башка норматив-хокукый актларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүен Татарстан Республикасы Конституция суды тикшерүе чикләре һәм әлеге эш буенча йомгаклау карарларының төрләре әлеге Законның 83 һәм 84 статьяларында билгеләнә.

Дүртенче кисәк

Йомгаклау нигезләмәләре

107 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты

1. Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлеге Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты тарафыннан тәэмин ителә.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты Татарстан Республикасы Конституция судын оештыру, фәнни-аналитик, мәгълүмати-белешмә, матди-техник, социаль-көнкүреш яктан һәм башкача тәэмин итүне гамәлгә ашыра, килүчеләрне кабул итә; Татарстан Республикасы Конституция суды адресына килгән мөрәҗәгатьләрне алдан карау тәртибендә һәм аларны Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары тарафыннан өйрәнү таләп ителмәгән очракларда карый; судьяларга утырышларда һәм киңәшмәләрдә карауга эшләрне һәм башка мәсьәләләрне әзерләүдә булы-

ша; дәүләт органнарының Татарстан Республикасы Конституция суды карарларын үтәүләрен тәэмин итү эшчәнлеген өйрәнә һәм гомумиләштерә.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды үз чыгымнары сметасы чикләрендә аппаратның санын, структурасын һәм штат расписаниесен билгели; Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты турындагы нигезләмәне раслый.

4. Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты хезмәткәрләренең хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы, шулай ук аларның дәүләт хезмәтен үтәү шартлары Дәүләт хезмәте турындагы Татарстан Республикасы Законы һәм башка норматив-хокукый актлары, шулай ук хезмәт турындагы законнар белән билгеләнә.

5. Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты хезмәткәрләренә хезмәт хаклары билгеләү Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

108 статья. Татарстан Республикасы Конституция судының рәсми басмасы

Татарстан Республикасы Конституциясенең рәсми басмасы - "Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре".

109 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды мөһере

Татарстан Республикасы Конституция суды - юридик зат, аның Татарстан Республикасы Дәүләт гербы төшерелгән һәм үз исеме язылган мөһере була.

110 статья. Татарстан Республикасы Конституция судының суд хакимияте символлары

1. Татарстан Республикасы Конституция суды урнашкан бинага Татарстан Республикасының Дәүләт флагы куела.

Татарстан Республикасы Конституция судының утырышлар залында Татарстан Республикасы Дәүләт гербы һөм Татарстан Рес-

публикасы Дәүләт флагы урнаштырыла.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары утырышларда мантияләр киеп утыра.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан хезмәт таныклыгы бирелә.

111 статья. Татарстан Республикасы Конституция судының урнашу урыны

Татарстан Республикасы Конституция судының даими урнашу урыны - Татарстан Республикасының башкаласы Казан шәһәре.

Татарстан Республикасы Конституция суды утырышлары даими урнашкан урында үткәреләләр, шулай ук башка урыннарга чыгып та үткәрелергә мөмкин".

**2 статья.** Әлеге Закон 1999 елның 1 гыйнвареннан үз көченә керә.

**3 статья.** Татарстан Республикасы Конституция суды сайланганчыга кадәр Татарстан Республикасының Конституция күзәтчелеге комитеты үз вәкаләтләрен "Татарстан Республикасында Конституция күзәтүе турында" 1990 елның 13 декабрендәге Татарстан Республикасы Законы нигезендә башкара.

**4 статья.** Татарстан Республикасы Конституция суды сайланган мизгелдән "Татарстан Республикасында Конституция күзәтүе турында" 1990 елның 13 декабрендәге Татарстан Республикасы Законы үз көчен югалта, дип билгеләргә.

**5 статья.** Әлеге Законны кабул итүгә бәйле рәвештә "Татарстан Республикасы Конституциясен гамәлгә кертү тәртибе турында" 1992 елның 30 ноябрендәге 1665-XII нче Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы (Татарстан Югары Советы җыелма

басмасы, 11-12 нче сан, 1992, 182 бит), шулай ук Татарстан Республикасы Югары Советының "Татарстан Республикасы Конституция суды турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында" 1992 елның 22 декабрендәге 1709-XII нче карары (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 11-12 нче сан,1992, 187 бит) үз көчен югалта, дип танырга.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 30 октябре
N 1840